# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге составына керүче Әлки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

03 ноябрь 2022 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Исәк авыл җирлегенең Әлки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Әлки авылында юлларны ремонтлау һәм каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыгын төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2022 елның 3 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 139 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 109 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 109 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Исәк авыл җирлеге составына керүче Әлки авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. «Исәк авыл җирлегенең Әлки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Әлки авылында юлларны ремонтлау һәм каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыгын төзекләндерү өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.
3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Әлки авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Исәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: __________ З.Р. Мөхәмәтҗанова

Исәк авыл җирлеге
башлыгы _________________ З.Р. Мөхәмәтҗанова